**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа  Җөлби торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“01” ноябрь 2020 ел — № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Олы Әтнәавыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №126 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа  Җөлби торак пунктында халык җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнәавыл җирлеге Яңа  Җөлби авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнәавыл җирлегенең Яңа  Җөлби авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- су башнясын сатып алу һәм урнаштыру (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

2) җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Киров урамын ремонтлау һәм каплау (сатып алу, ташу төзелеш материалларын урнаштыру һәм килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3) торак пункт территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- хуҗасыз этләрне тоту

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа  Җөлби авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Олы Әтнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа  Җөлби авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча  һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма
комитет җитәкчесе: — Хайрутдинов А.Г.